БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» 02 2026ел № 73

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәү урыны буенча бала тууны теркәгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гражданнарына бала (балалар) тугач бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында демографик вәзгыятьне яхшырту һәм халык саны кимүнең тискәре тенденцияләрен бетерү максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнарга бала (балалар) тугач бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2025 елның 15 маендагы 154 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәү урыны буенча бала тууны теркәгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гражданнарына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү Тәртибенә (2025 елның 18 декабрендәге 346 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктта «2025» сүзләрен «2026» га алмаштырырга;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12. 2026 елда туган балага (балаларга) бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алу өчен гаризалар 2027 елның 1мартына кадәр кабул ителә.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җитәкче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов